ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2022 г. Казань № 312-24/тэ-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү эшчәнлегенең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыруны туктату сәбәпле, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 9 ноябрендәге 34-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Иннополис» сәнәгый-житештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга бирелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020-2024 елларга тарифлар билгеләү хакында» 09.12.2019 № 5-98/тэ;

«2021 елга «Иннополис» махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2019 № 5-98/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга үзгәреш кертү хакында» 15.12.2020 № 439-80/тэ-2020;

«2022 елга «Иннополис» махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2019 № 5-98/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга үзгәреш кертү хакында» 24.11.2021 № 354-82/тэ-2021.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев